# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 сентября 2016 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1, № 9 (II часть); 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4; Республика Татарстан, 2016, 9 июля) следующие изменения:

1) статью 10 изложить в следующей редакции:

«Статья 10. **Квалификационные требования к должностям государственной службы**

1. Для замещения должности государственной службы требуется соответствие квалификационным требованиям к уровню профессионального образования, стажу государственной службы или работы по специальности, направлению подготовки, знаниям и умениям, которые необходимы для исполнения должностных обязанностей, а также при наличии соответствующего решения представителя нанимателя – к специальности, направлению подготовки.

2. Квалификационные требования для замещения должностей государственной службы устанавливаются в соответствии с категориями и группами должностей государственной службы, областью и видом профессиональной служебной деятельности государственного служащего.

3. Для замещения должностей государственной службы категорий «руководители», «помощники (советники)», «специалисты» высшей и главной групп должностей государственной службы обязательно наличие высшего образования не ниже уровня специалитета, магистратуры.

4. Для замещения должностей государственной службы категорий «руководители», «помощники (советники)» ведущей группы должностей государственной службы, категории «специалисты» ведущей и старшей групп должностей государственной службы, а также категории «обеспечивающие специалисты» главной и ведущей групп должностей государственной службы обязательно наличие высшего образования.

5. Для замещения должностей государственной службы категории «обеспечивающие специалисты» старшей и младшей групп должностей государственной службы обязательно наличие профессионального образования.

6. Устанавливаются следующие квалификационные требования к стажу государственной службы или работы по специальности, направлению подготовки, который необходим для замещения должностей государственной службы, для государственных служащих:

для замещения должностей государственной службы категорий «руководители» и «помощники (советники)» высшей группы должностей государственной службы – стаж государственной службы не менее трех лет либо стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее семи лет;

для замещения должностей государственной службы категории «специалисты» высшей группы должностей государственной службы – стаж государственной службы не менее трех лет либо стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее пяти лет;

для замещения должностей государственной службы всех категорий главной группы должностей государственной службы – стаж государственной службы не менее двух лет либо стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее трех лет;

для замещения должностей государственной службы всех категорий ведущей группы должностей государственной службы – стаж государственной службы не менее одного года либо стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее двух лет.

Квалификационные требования к стажу государственной службы или стажу работы по специальности, направлению подготовки для замещения должностей государственной службы старшей и младшей групп должностей государственной службы не устанавливаются.

При определении стажа государственной службы учитывается также стаж работы на должностях федеральной государственной гражданской службы соответствующих должностных групп, воинских должностях и должностях федеральной государственной службы иных видов, государственных должностях, муниципальных должностях, должностях муниципальной службы соответствующих должностных групп, иных должностях в соответствии с федеральными законами.

7. Квалификационные требования к стажу государственной службы или работы по специальности, направлению подготовки, установленные частью 6 настоящей

статьи, при замещении должностей государственной службы категории «помощники (советники)» главной и ведущей групп должностей государственной службы и категории «специалисты» главной и ведущей групп должностей государственной службы лицами, имеющими ученую степень, соответствующую направлению деятельности, по решению руководителя государственного органа могут не учитываться.

8. Для лиц, имеющих дипломы специалиста или магистра с отличием, в течение трех лет со дня выдачи диплома устанавливаются квалификационные требования к стажу государственной службы или работы по специальности, направлению подготовки для замещения ведущих должностей государственной службы – не менее одного года стажа государственной службы или работы по специальности, направлению подготовки.

9. Квалификационные требования к знаниям и умениям, необходимым для исполнения должностных обязанностей, устанавливаются в зависимости от области и вида профессиональной служебной деятельности государственного служащего его должностным регламентом. Должностным регламентом государственного служащего (далее – должностной регламент) могут также предусматриваться квалификационные требования к специальности, направлению подготовки, которые необходимы для замещения должности государственной службы.»;

2) дополнить статьей $17^2$ следующего содержания:

«Статья $17^2$. **Представление сведений о размещении информации в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»**

1. Сведения об адресах сайтов и (или) страниц сайтов в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», на которых гражданин, претендующий на замещение должности государственной службы, государственный служащий размещали общедоступную информацию, а также данные, позволяющие их идентифицировать, представителю нанимателя представляют:

1) гражданин, претендующий на замещение должности государственной службы, – при поступлении на службу за три календарных года, предшествующих году поступления на государственную службу;

2) государственный служащий – ежегодно за календарный год, предшествующий году представления указанной информации, за исключением случаев размещения общедоступной информации в рамках исполнения должностных обязанностей государственного служащего.

2. Сведения, указанные в части 1 настоящей статьи, представляются гражданами, претендующими на замещение должности государственной службы, при поступлении на государственную службу, а государственными служащими – не позднее 1 апреля года, следующего за отчетным. Сведения, указанные в части 1 настоящей статьи, представляются по форме, установленной Правительством Российской Федерации.

3. По решению представителя нанимателя уполномоченные им государственные служащие осуществляют обработку общедоступной информации, размещенной претендентами на замещение должности государственной службы и государствен-

ными служащими в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», а также проверку достоверности и полноты сведений, предусмотренных частью 1 настоящей статьи.»;

3) в статье 18:

а) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. Государственным служащим, для которых установлен ненормированный служебный день, предоставляется ежегодный дополнительный оплачиваемый отпуск за ненормированный служебный день в соответствии со статьей 19 настоящего Закона.»;

б) часть 5 признать утратившей силу;

4) в статье 19:

а) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Государственным служащим предоставляется ежегодный основной оплачиваемый отпуск продолжительностью 30 календарных дней.»;

б) часть 4 признать утратившей силу;

в) часть 5 изложить в следующей редакции:

«5. Государственным служащим в соответствии с Федеральным законом предоставляется ежегодный дополнительный оплачиваемый отпуск за выслугу лет продолжительностью:

1) при стаже государственной службы от 1 года до 5 лет – 1 календарный день;

2) при стаже государственной службы от 5 до 10 лет – 5 календарных дней;

3) при стаже государственной службы от 10 до 15 лет – 7 календарных дней;

4) при стаже государственной службы 15 лет и более – 10 календарных дней.»;

г) в абзаце первом части 6 второе предложение исключить;

д) дополнить частью $6^1$ следующего содержания:

«$6^1$. Государственным служащим, для которых установлен ненормированный служебный день, в соответствии с Федеральным законом предоставляется ежегодный дополнительный оплачиваемый отпуск за ненормированный служебный день продолжительностью три календарных дня.»;

5) пункт 1 части 2 статьи 20 изложить в следующей редакции:

«1) квалификационные требования для замещения должности государственной службы;».

**Статья 2**

1. Сохранить для государственных служащих, имеющих на день вступления в силу Федерального закона от 2 июня 2016 года № 176-ФЗ «О внесении изменений в статьи 45 и 46 Федерального закона «О государственной гражданской службе Российской Федерации» в части упорядочения продолжительности отпусков на государственной гражданской службе» неиспользованные ежегодные оплачиваемые отпуска или части этих отпусков, право на их использование, а также право на вы-

плату денежной компенсации за неиспользованные ежегодные оплачиваемые отпуска или части этих отпусков.

2. Исчислять в соответствии с требованиями статьи 46 Федерального закона от 27 июля 2004 года № 79-ФЗ «О государственной гражданской службе Российской Федерации» (в редакции Федерального закона от 2 июня 2016 года № 176-ФЗ «О внесении изменений в статьи 45 и 46 Федерального закона «О государственной гражданской службе Российской Федерации» в части упорядочения продолжительности отпусков на государственной гражданской службе») и статьи 19 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции настоящего Закона) продолжительность ежегодных оплачиваемых отпусков, предоставляемых государственным служащим, замещающим должности государственной службы на день вступления в силу Федерального закона от 2 июня 2016 года № 176-ФЗ «О внесении изменений в статьи 45 и 46 Федерального закона «О государственной гражданской службе Российской Федерации» в части упорядочения продолжительности отпусков на государственной гражданской службе», начиная с их нового служебного года.

3. Квалификационное требование для замещения должностей государственной службы категорий «руководители», «помощники (советники)», «специалисты» высшей и главной групп должностей государственной службы о наличии высшего образования не ниже уровня специалитета, магистратуры не применяется:

1) к гражданам, претендующим на замещение указанных должностей государственной службы, и государственным служащим, замещающим указанные должности, получившим высшее профессиональное образование до 29 августа 1996 года;

2) к государственным служащим, имеющим высшее образование не выше бакалавриата, назначенным на указанные должности до дня вступления в силу Федерального закона от 30 июня 2016 года № 224-ФЗ «О внесении изменений в Федеральный закон «О государственной гражданской службе Российской Федерации» и Федеральный закон «О муниципальной службе в Российской Федерации», в отношении замещаемых ими должностей государственной службы.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 сентября 2016 года
№ 73-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4; Ватаным Татарстан, 2016, 9 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10 статья. **Дәүләт хезмәте вазыйфаларына квалификация таләпләре**

1. Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, дәүләт хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук яллаучы вәкиленең тиешле карары булган очракта – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.

2. Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре дәүләт хезмәте вазыйфаларының категорияләре һәм төркемнәре, дәүләт хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төре нигезендә билгеләнә.

3. Дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары һәм баш төркемнәренең “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)”, “белгечләр” категорияләре дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен специалитет, магистратура дәрәҗәсеннән ким булмаган югары белем булырга тиеш.

4. Дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменең “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләре, дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәүче һәм өлкән төркемнәренең “белгечләр” категориясе, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш һәм әйдәүче төркемнәренең “тәэмин итүче белгечләр” категориясе дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен югары белем булырга тиеш.

5. Дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәренең “тәэмин итүче белгечләр” категориясе дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем булырга тиеш.

6. Дәүләт хезмәткәрләре өчен дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәкле дәүләт хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменең “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләре дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә өч ел дәүләт хезмәте стажы йә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә җиде ел эш стажы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменең “белгечләр” категориясе дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә өч ел дәүләт хезмәте стажы йә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш төркеменең барлык категорияләре дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә ике ел дәүләт хезмәте стажы йә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә өч ел эш стажы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменең барлык категорияләре дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә бер ел дәүләт хезмәте стажы йә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.

Дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәре дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен дәүләт хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Дәүләт хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрдәге федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында, хәрби вазыйфаларда һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфаи төркемнәрдәге муниципаль хезмәт вазыйфаларында, федераль законнар нигезендә башка вазыйфаларда эш стажы исәпкә алына.

7. Дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш һәм әйдәүче төркемнәренең “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясе һәм дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш һәм әйдәүче төркемнәренең “белгечләр” категориясе дәүләт хезмәте вазыйфаларын эшчәнлеге юнәлешенә туры килә торган гыйльми дәрәҗәсе булган затлар биләгәндә, дәүләт хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата әлеге статьяның 6 өлешендә билгеләнгән квалификация таләпләре дәүләт органы җитәкчесе карары буенча исәпкә алынмаска да мөмкин.

8. “Бик яхшы” билгеләре генә куелган белгеч яисә магистр дипломы булган затларга диплом бирелгән көннән алып өч ел дәвамында дәүләт хезмәтенең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен дәүләт хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек

юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре дәүләт хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы итеп билгеләнә.

9. Вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, дәүләт хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә, аның вазыйфаи регламентында билгеләнә. Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентында (алга таба – вазыйфаи регламент) шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә кирәкле квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.";

2) түбәндәге эчтәлекле $17^2$ статья өстәргә:

"$17^2$ статья. **"Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында белешмәләр тапшыру**

1. Дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергән граждан йә дәүләт хезмәткәре тарафыннан һәркем файдалана алырлык мәгълүмат урнаштырылган сайтларның һәм (яисә) сайтлардагы битләрнең "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге адреслары турында белешмәләрне, шулай ук аларны тәңгәлләштерергә мөмкинлек бирә торган белешмәләрне яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшырырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергән граждан – дәүләт хезмәтенә кергәндә, дәүләт хезмәтенә кергән елга кадәрге өч календарь ел өчен;

2) дәүләт хезмәткәре – ел саен, күрсәтелгән мәгълүмат тапшырылган елга кадәрге календарь ел өчен, моңа дәүләт хезмәткәренең һәркем файдалана алырлык мәгълүматны вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштыру очраклары керми.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергән гражданнар тарафыннан дәүләт хезмәтенә кергәндә, ә дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән рәвеш буенча тапшырыла.

3. Яллаучы вәкиле тарафыннан вәкаләт бирелгән дәүләт хезмәткәрләре, аның карары буенча, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергәннәр һәм дәүләт хезмәткәрләре "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырган һәркем файдалана алырлык мәгълүматны өйрәнәләр, шулай ук әлеге статьяның 1 өлешендә каралган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерәләр.";

3) 18 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән дәүләт хезмәткәрләренә нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен әлеге Законның 19 статьясы нигезендә ел саен өстәмә түләүле отпуск бирелә.”;

б) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

4) 19 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Дәүләт хезмәткәрләренә ел саен 30 календарь көн дәвамында төп түләүле отпуск бирелә.”;

б) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Федераль закон нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен түбәндәге дәвамлылыкта ел саен өстәмә түләүле отпуск бирелә:

1) дәүләт хезмәте стажы 1 елдан 5 елга кадәр булганда – 1 календарь көн;

2) дәүләт хезмәте стажы 5 елдан 10 елга кадәр булганда – 5 календарь көн;

3) дәүләт хезмәте стажы 10 елдан 15 елга кадәр булганда – 7 календарь көн;

4) дәүләт хезмәте стажы 15 ел һәм аннан күбрәк булганда – 10 календарь көн.”;

г) 6 өлешнең беренче абзацындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

“$6^1$. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән дәүләт хезмәткәрләренә нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен Федераль закон нигезендә ел саен өч календарь көн дәвамлылыгында өстәмә түләүле отпуск бирелә.”;

5) 20 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре;”.

**2 статья**

1. “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законның 45 һәм 46 статьяларына дәүләт граждан хезмәтендә отпускларның дәвамлылыгын җайга салу өлешендә үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 2 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә файдаланылмаган еллык түләүле отпусклары яисә бу отпускларның бер өлеше калган дәүләт хезмәткәрләре өчен аларны алу хокукын, шулай ук файдаланылмаган еллык түләүле отпусклар яисә бу отпускларның бер өлеше өчен акчалата компенсация алу хокукын саклап калырга.

2. “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законның 45 һәм 46 статьяларына дәүләт граждан хезмәтендә отпускларның дәвамлылыгын җайга салу өлешендә үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 2 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән дәүләт хезмәткәрләренә бирелә торган еллык

түләүле отпускларның дәвамлылыгын “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы (“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законның 45 һәм 46 статьяларына дәүләт граждан хезмәтендә отпускларның дәвамлылыгын җайга салу өлешендә үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 2 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) һәм “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы (әлеге Закон редакциясендә) таләпләре нигезендә аларның яңа хезмәт елыннан башлап санарга.

3. Дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары һәм баш төркемнәренең “җитәкчеләр”, “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)”, “белгечләр” категорияләре дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен специалитет, магистратура дәрәҗәсеннән ким булмаган югары белем булу турындагы квалификация таләпләре түбәндәгеләргә кагылмый:

1) югары һөнәри белемне 1996 елның 29 августына кадәр алган дәүләт хезмәтенең күрсәтелгән вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдергән гражданнарга һәм күрсәтелгән вазыйфаларны били торган дәүләт хезмәткәрләренә;

2) “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 30 июнендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр әлеге вазыйфаларга билгеләнгән югары белеме бакалавриаттан югары булмаган дәүләт хезмәткәрләренә, үзләре били торган дәүләт хезмәте вазыйфаларына карата.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 29 сентябре
№ 73-ТРЗ